**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле ав. **КАРАР**

«16» октябрь 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2023 елның 9 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Заречная урамы, 14 адресы буенча урнашкан торак йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Заречная, Родниковая, Космонавтлар урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2023 елның 9 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Сәүдә урамы, 19 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Торговая, Молодежная, Олимпийская, Рабочая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2023 елның 10 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Совет урамы, 44 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Советская, Садовая, Солнечная, Школьная урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. 2023 елның 10 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Комсомол урамы, 6 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Комсомольская, З. Каримова, Колхозная, Луговая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.
5. 2023 елның 10 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Заозерная урамы, 5 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Заозерная,

Сибирская, Нижняя урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

2. Киекле авылында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, СВО зонасында катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Киекле авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);

- Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

-Киекле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- ремонт, коймалар тоту, Киекле торак пунктында урнашкан өч зират тирәсен төзекләндерү;

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова